РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЦ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

03.09.2019

КАРАР

№ 1029-п

Саба муниципаль районында
гражданлык оборонасы буенча чараларның
үтәлешен тәэмин итү өчен
штаттан тыш берләшмәләр төзү турында

“Гражданлык оборонасы турында”гы 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерацииясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципларынның турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Министрлыгының Гражданлык оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча ,2014 елның 18 декабрендәге 701 номерлы “Гражданлык оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү өчен штаттан тыш берләшмәләр төзүнең типик тәртибен раслау турында”гы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 19 гыйнварындагы 35-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм Гражданлык оборонасы буенча чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә, гражданлык оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү очен төзелгән территориаль штаттан тыш берләшмәләр исемлеген расларга.

2. Берләшмәләр тозелә торган оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Берләшмәләр җиһазлауны, Россия Федерациясе Министрлыгының, Гражданлык оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча, 2014 елның 18 декабрендәге 701 номерлы "Гражданлык оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү очен штаттан тыш берләшмәләр тозүнең тәртибен раслау турында" гы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырырга;

- Төзелүче берләшмәләр шәхси составының штат-вазыйфаи исемлеген расларга;

- Карар кабул ителгәннән соң ,бер ай эчендә, берләшмәләрне эшләргә әзерлек дәрәҗәсенә җиткерү планнарын төзергә һәм килештерергә,план күчермәләрен Саба янгын сүндерү-коткару гарнизонына тапшырырга;

- Берләшмәләрнең әзерлеген укыту программасы нигезендә оештырырга.

3. Гражданлык оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү өчен территориаль штаттан тыш берләшмәләрнең, Саба муниципаль районы гражданлык оборонасы җитәкчесенең, гражданлык оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә, Саба муниципаль районы территориясендә гражданлык оборонасы олкәсендәге бурычларны хәл итү өчен, шулай ук, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда аларны закон нигезендә бетерү өчен җәлеп ителүләрен билгеләргә.

4. Саба янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны башлыгына берләшмәләрне төзүдә методик ярдәм оештыруны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең, 2010 елның 19 июлендәге 916-п номерлы “Штаттан тыш авария-коткару берләшмәләре төзү турында” гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
________________________
карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гражданлык оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү очен тозелгән территориаль штаттан тыш берләшмәләрнең исемлеге**

| № | ГОШТБ ның исеме | ГОШТБ тозелә торган оешма (килешү буенча) | ГОШТБ ның шәхси состав саны (кеше) | ГОШТБ ның структурасы | | | ГОШТБ ның билгеләнеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Состав (постлар, төркемнәр, звенолар, командалар) | ГОШТБ структурасына керүче оешмалар (килешү буенча) | Составында бүлеп бирелә торган көчләр һәм чаралар (килешү буенча) | |
| Территориаль берләшмәләр | | | | | | | |
| 1 | Халыкны йөртүче төркем | «Рамазан» ЖЧЖ | 25 | Звенолар | «Рамазан» ЖЧЖ | Автобус - 20 | Гражданлык оборонасы буенча чараларның, Халыкны зарарлану урынынан эвакуацияләүне тәэмин итүгә кагылышлы өлешен үтәү |
| 2 | Җәмәгать тәртибен саклау төркеме | “Олимп” спорт комплексы | 10 | Звено | “Олимп” спорт комплексы | Ш/а-1 | Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү |
| | | | | Звено | Яшьлек " яшьләр спорт үзәге | Ш/а-1 ед. | Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү |
| 3 | Су ташу төркеме | "Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба куптармаклы | 2 | Звено | "Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба куптармаклы житештерү | Авто цистерна - 2 | ГОШТБның шәхси составын, зарарлану чыганагында халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | житештерү предприятиесе" ААҖ | | | предприятиесе" ААҖ | | |
| 4 | Күчмә туклану, азык-төлек (әйберләр) белән тәэмин итү пунктлары | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | 15 | Ризык әзерләү һәм тарату звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | 5 кеше | АСДНР ны үтәү барышында зарарлану чыганагында зыян күргән халыкны һәм ГОШТБ ның шәхси составын кайнар аш белән тәэмин итү |
| | | | | Ризык әзерләү һәм тарату звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | 5 кеше | |
| | | | | Тәэмин итү звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | УАЗ автомашинасы-2 | |
| | | | | | “ТР буенча 7 ОФПС” ФГКУ 129 янгын сүндерү һәм коткару бүлеге | КП-130.11 кыр кухнясы-1 | |
| | | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | 6 | Звено | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | Газель автомашинасы - 2 . | Зарарлану чыганагында зыян күргән халыкны азык-төлек белән тәэмин итү |
| | | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | 12 | Фасовка һәм тарату звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | УАЗ автомашинасы – 1 | Зарарлану чыганагындагы зыян күргән халыкны иң кирәкле әйберләр, кием-салым һәм башка кирәк-яраклар белән тәэмин итү |
| | | | | Фасовка һәм тарату звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | УАЗ автомашинасы – 1 | |
| | | | | Тәэмин итү звеносы | Саба Районы Кулланучылар Җәмгыяте | Газель автомашинасы – 2 | |
| 5 | Элемтә һәм хәбәр итү звеносы | "Таттелеком" ААЖ Арча ЗУЭСының Саба РУЭС | 15 | Звено | "Таттелеком" ААҖ Арча ЗУЭСының Саба РУЭС | УАЗ автомашинасы – 1 | Гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча житәкчене элемтә белән тәэмин итү |
| | | 7 | 85 к. | | | | |